Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлегенең Ивановка авылында гражданнар җыены

КАРАРЫ

2023 елның 19 ноябре №2

**2024 елда Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Ивановка авыл җирлегенең Ивановка авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану турында**

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлеге Ивановка авылы гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2024 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Ивановка авыл җирлеге Ивановка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 төркем инвалидлар, күп балалы гаиләләрдән тыш, һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

I. торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

Ивановка авылында Нагорная урамы, Яшьлек урамы, Мәктәп тыкрыгы буенча вак таш юлларны чокырлы ремонтлау;

Ивановка авылында (Үзәк, Октябрь, Яшьлек, Заречная, Таулы, Энтузиастлар, Чишмә, Мәктәп тыкрыгы) юлларны кардан чистарту.

II. Җирлек территориясен төзекләндерүне күрсәтелгән кагыйдәләргә ярашлы итеп, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, инвалидлар өчен социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларына һәм күрсәтелә торган хезмәтләргә ирешү мөмкинлеген тәэмин итү таләпләрен үтәү:

Ивановка авылы территориясендә үлән чабу;

- бензокос (триммер) сатып алу.

III. Торак пунктлар чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү:

янгын сүндерү машинасы өчен запас частьләр сатып алу;

янгын сүндерү җиһазлары һәм янгын сүндерү инвентары сатып алу;

янгын сүндерү машинасы өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу.
гидранты урнаштыру (Заречная ур.).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Ивановка авылы, Яшьлек урамы, 5, Аккүл авылы, Колхоз урамы, 16Б, Медведка авылы, Дорожная урамы, 32, Михайловка авылы, Центральная урамы, 4 йорт адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында «Авыл җирлекләре»

бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы
Ивановка авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге
башлыгы А.П.Бодряева